Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

28 ноябрь 2019 ел N 6

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Яңа Никольский авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 21 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Яңа Никольский авылының Үзәк урамында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 21 декабрендә 11 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Яңа Никольский авылының Яшьләр урамында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский авыл җирлегенең Яңа Никольский авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Яңа Никольский авылында урам утлары челтәрен норматив хәлгә китерүгә, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын Яңа Никольский авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Яңа Никольский авылы, Үзәк урамы, 100 нче йортта уздырырга.
5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Яңа Никольский авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл башкарма комитетын билгеләргә.
7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Яңа Никольский авылы, Үзәк урамы, 100 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгы Х.Х. Дәүләтгәрәев